Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

17 апрель 2023 ел №3

Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаши авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 13 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апрелендәге 181 номерлы протестын карап

Ямаши авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Ямаши_ авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ямаши авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 13 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Ямаши авылы Совет урамы, 4 нче йорт; Рокашево авылы, Үзәк урам, 1 нче йорт; Красная Горка авылы, Тихая Аллея урамы, 9 нчы йорт торак пункт территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ямаши авыл башкарма
комитеты җитәкчесе А.А. Андревкина